

# *КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘР*

**№4 2024 ел**

***<u>98 нче татар – рус урта гомуми белем бирү мәктәбе</u>***




Кадерле **"Каләм тибрәтүчеләр"** гәҗитен укучылар! Менә 2024 нче ел, ягъни Гаилә елы да ахырына якынлашып килә. Без 2024 нче елда нинди уңышларга ирешүебезне, югалтуларны, күңелле һәм күңелсез вакыйгаларны барлыйбыз, елга нәтиҗә ясыйбыз.

Яңа 2025 нче елда шатлыклы очрашулар, бәхетле елмаюлар, куанычлы мизгелләр күп булсын! Бәрәкәтле еллар сезгә! Һәрберебезгә сәламәтлек, тынычлык, мәхәббәт, иминлек, бәхет, шатлык, күңел тынычлыгы һәм уңышлар телибез! Тормыштан ямь-тәм табып һәм кадерле булып яшәргә насыйп булсын! Яңа ел белән, кадерле дусларым!

Җир йөзенә Яңа еллар килә

Акка төреп сихри дөньяны.

Үткәннәре калсын үткәннәрдә,

Өмет белән каршылыйк яңаны!

Кайгылар да калсын иске елда,

Бәхет алып килсен яңасы.

Борма-борма тормыш юлларыннан

Бергәләшеп безгә барасы.

Парсызлар да үз парларын тапсын,

Парлыларга - парлы мәхәббәт.

Кайгыларсыз булсын һәр көнебез

Йортыбызга иңсен бәрәкәт!





Рөстәм Нургали улы  Миңнеханов 2025 елны Ватанны Саклаучы елы дип игълан итте. Бу хакта ул 2025 елга Дәүләт Советына еллык юлламасында әйтте.
«Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк», – дип язган бөек галимебез Шиһабетдин Мәрҗани. Тарихи хәтерне саклау – киләчәк буыннар алдындагы бурычыбыз. Бу безгә буыннар бәйләнешен тирәнтен тоярга, киләчәккә ышаныч белән карарга ярдәм итә», – диде Рөстәм Миңнеханов.
Татарстан Рәисе 2025 елда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы билгеләп үтеләчәген искәртте.
«Ул Җиңү – безнең төп горурлык. Бүген бездә булганнар белән фронтта һәм тылда җиңү өчен көч куйган ветераннарга бурычлыбыз. Кызганыч, Бөек Җиңүнең тере шаһитләре көннән-көн кими. Һәр ветеранны кайгырту мөһим. Муниципаль берәмлек башлыкларына, башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә тиешле чараларга әзерлекне югары дәрәҗәдә оештыруларын сорыйм», – дип мөрәҗәгать итте рәисебез Рөстәм  Миңнеханов.
Әйе, чыннан да, һәркем үткәнен белергә, тарихны өйрәнергә, истәлекләрне кадерләп сакларга, аларны киләчәк буыннарга тапшырырга  тиеш. Шулар үрнәгендә илебезне хөрмәт итә торган лаеклы  гражданнар тәрбияләү - безнең бурычыбыз!

**Тату туганнар таштан койма корганнар**

Гаилә елында туганнар  темасын күтәрмичә мәмкин түгел. Чөнки гаилә елы тәмамланып килә. Бу тема - мәңгелек тема. Гаилә дип әйтүгә, күз алдына эти-әнием, әби-бабайларым, аларның бертуганнары, икетуган апа-сеңелләре, абый-энеләре, аларның балалары, гомумән, барлык  туганнар  килеп баса.
Әти белән әни безне кечкенәдән туганнар белән аралашырга, ярдәмләшеп яшәргә өйрәтте. Авыр вакытмы, яисә шатлыклы вакытмы, без һәрчак туганнар белән аралашып яшибез. Авылда күмәк эшләрне дә бергәләп башкарабыз. Еш кына кунакларга йөрешәбез.
Минемчә, татар халкында "Тату туганнар таштан койма корганнар", яисә "Туган бар җирдә ярдәм бар" дип тикмәгә генә әйтмиләр. Туганлыгың көчле булса, бар эшне дә җиңеп чыгарга була. Туганнарың белән тату булып яшәргә язсын!

Туганнарның кадерләрен белеп
Тату гына кирәк яшәргә!
Апам, абый, энем, сеңлем,  диеп,
Ничек рәхәт бит ул яшәргә!




**Әй мәктәбем, белем учагым,**

**Син гомернең иң гүзәл чагы.**

Әйе, чыннан да, мәктәп еллары иң гүзәл һәм хәтердә уелып кала торган матур мизгелләр. Ә шушы вакытларны истәлек итеп саклау өчен без күңелебездә ул мизгелләрне истә тотарга тиеш.

Менә шушы мизгелләрнең шахиты - үзем 25 ел хезмәт иткән Казан шәһәренең Вахитов районында урнашкан 98 нче татар- рус урта мәктәбендә мәктәпнең 85 еллык юбилее үткәрелү. Мәктәбебезгә бик күп чыгарылыш сыйныф укучылары, бүгенге көндә мәктәбебездә укыткан һәм лаеклы ялда булган укытучылар, район һәм шәһәр мәгариф идарәсеннән вәкилләр, кунаклар да килгән иде. "Бер күрешү-үзе бер гомер " дигәндәй, һәрберсе бу күрешүгә бик канатланып һәм зур теләк белән килгән иде.

Укучылар мәктәбебезнең 85 еллыгына бик матур итеп концерт куйдылар. Концертның эчтәлеге дә бер-берсенә үрелеп барды. Район мәгариф идарәсеннән килгән Войцеховская Алина Алексеевна мәктәбебез директоры Авзалова Айгөл Илдаровнаны Мактау грамотасы белән бүләкләде. Шулай ук мәктәбебездә озак еллар хезмәт куйган укытучыларыбызга да Мактау грамоталары тапшырылды.

Мәктәбебезнең ветеран укытучысы Федорова Валентина Алексеевна мәктәбебезнең сугыш елларында госпиталь булуы турында сөйләп үтте. Үзенең 44 ел гомерен шушы 98 нче мәктәптә балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлавын әйтте. Аның тормыш девизы булып кешеләргә яхшылык эшләү икәнен азсызыклап үтте. Валентина Алексеевна шулай ук ветеран укытучылар турында сөйләде, бүгенгесе көндә мәрхүм булган укытучыларны искә алып, безнең сүзләр аларга дога булып барып ирешсен иде, диде.

Безнең мәктәбебездә озак еллар эшләгән, бүгенге көндә шәһәр мәгариф идарәсендә хезмәт итүче Залялетдинова Гөлнара Фирдавсовна да үзенең изге теләкләрен җиткерде. Ни өчен 98 мәктәп аның өчен бик якын һәм кадерле булуын сөйләп үтте.

Район мәгариф идарәсеннән килгән профсоюз оешмасы җитәкчеләре Шарипова Гөлнур Ахнафовна һәм Васюхина Наталья Григорьевна ветеран укытучыларыбызны котлап рәхмәт хатлары һәм бүләкләр тапшырдылар, үзләренең изге теләкләрен җиткерделәр. Мәктәбебез директоры Айгөл Илдаровнага, администрациягә һәм укытучыларыбызга рәхмәтләрен ирештерделәр.

Мәктәбебез директоры Айгөл Илдаровна Авзалова барлык килгән кунакларга, укытучыларга, чыгарылыш укучыларына рәхмәтен белдерде. Бүгенгесе көндә мәктәбебезнең алга таба үсеше, ирешкән уңышлар турында сөйләп үтте. Киләчәктә дә мәктәбебез алдынгы урында торачак һәм яңадан-яңа уңышларга ирешәчәк дип сүз бирде.

Әйе, без ышанабыз! Киләчәктә безнең мәктәбебез тагын да югары үрләр яулар! Җитәкчебез Айгөл Илдаровна һәм без- укытучылар, моның өчен бөтен көчебезне куячакбыз!



### ***2025 ел — яшел агач елан елы. Ул безне нилəр белән гаҗәпләндерер, беләсегез киләме?***

Кытай мәдәниятендә зирәк һәм хәйләкәр елан еш кына тылсымлы ярдәмче һәм серләрне саклаучы ролен уйный: авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә һәм дөрес юл күрсәтә. Елан — тыныч хайван, ләкин үзен яклый белә, шуңа күрә аны ачуландырмау яхшырак.

Ләкин ни өчен ул агачтан, өстәвенә яшел төстә, дисезме? Көнчыгыш йолдызнамәсендә һәр ел саен, ”хуҗа" хайваннан тыш, тагын бер элемент яки стихия алмашына: алтын, ут, су, җир һәм агач. Агачның символик төсе — яшел. Бу кагыйдәләр буенча "агачлылык" уңыш һәм үсеш вәгъдә итә, ә яшел төс сыгылмалылык, тынычлык һәм, иминлекне югалтмыйча, шартларга җайлашу сәләте турында сөйли. Күрүегезчә, алдагы елның билгеләре начар түгел.



Елан елыннан нәрсә көтәргә? Бер яктан, Еланны тыныч, акыллы хайван дип атыйлар. Икенче яктан — Елан вакытының еш кына дөньяга драматик вакыйгалар һәм катаклизмнар китерүе билгеле.
Мәсәлән, 1881 елда народоволецлар император Александр IIне шартлаталар. 1905 елда революция була. Октябрь революциясе дә Елан елында булган. 1929 елда АКШта — Бөек депрессия, ә 1941 елда СССРда Бөек Ватан сугышы башлана.
Шулай ук хуҗасы Елан булган 2001 елда 11 сентябрьдә АКШ тарихында иң зур теракт булды. 12 ел узгач, Бенедикт XVI Папа тәхетеннән ваз кичте — соңгы 600 ел эчендә Папаның ваз кичүенең беренче очрагы.

Борчулы исемлек 2025 елда тулыланмас дип өметләнәсе килә. Әмма астрологлар борылышлы вакыйгалар башка булмаячак, дип кисәтә.

Ел символының мотлак җимерелү генә вәгъдә итмәве юата ала: бу зур үзгәрешләр булырга мөмкин, көчләрнең гаять зур киеренкелеге һәм яңа ресурслар эзләү белән бәйле булса да.

Ничек кенә булмасын, «начарга әзерлән, яхшыга өмет ит» дигән канатлы әйтем актуаль булачак. Әгәр дә елның тәңкәле хуҗабикәсе хәвеф-хәтәрләр һәм үзгәрешләр китерсә, аларга алдан әзер булу яхшырак.

Дөньялар тыныч булсын! Сау-сәламәт булып, күңел тынычлыгында, бәрәкәтле тормышта, якыннарыбыз янәшәсендә яшәргә язсын!




**Редколлегия:**

**Касыймова Гөлнур Наил кызы**

**Әмирхан Еники, 23.**
**Тел: 8 (843) 236-24-12**

**Сездән язмалар көтеп калабыз!**